РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Глава
Вахитовского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Центральная, д. 30, Азнакаевский район,
п.Победа, 423312,
тел./факс (885592)42-1-38
E-mail: Vahit.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге
башлыгы

Үзәк ур., 30 йорт, Азнакай районы, Җиңү
бистәсе, 423312
тел./факс (885592)42-1-38
E-mail: Vahit.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«16» март 2023 ел.** **№ 3**

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Вахит авыл җирлеге Советының 2022 елга
Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Вахит авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында"
карары проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү хакында»

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы "Вахит авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге халык алдында тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә, халык алдында тыңлаулар үткәрү юлы белән Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлегендә яшәүчеләрнең хокукларын гамәлгә ашыру максатыннан Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге Советының 2012 елның 19 апрелендәге 42 нче номерлы карары белән расланган «2022 елда Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге бюджетының үтәлеше турында» гы карары проекты буенча фикер алышуда катнашу өчен халык алдында тыңлаулар үткәрү максатыннын карар итәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлегенең 2022 елгы бюджеты үтәлеше турында"гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Халык алдында ачык тыңлаулар үткәрү инициаторы - Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге башлыгы.

3. Билгеләргә:

- үткәрү вакыты-2023 елның 10 апреле 15:00 сәгатьтә;
- үткәрү урыны- Вахитов авыл җирлеге башкарма комитеты;

- тикшерелә торган  мәсьәлә буенча язмача тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тәкъдим ителә торган адрес: 423312, ТР, Азнакай районы, Победа поселогы , Үзәк урам, 30 нчы йорт.

4. Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге башкарма комитетына:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге Советының "2022 елда Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында" гы карары проекты буенча, гамәлдәге законнар, Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлегенең норматив-хокукый актлары нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокта ачык тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә;

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге Советының "2022 елда Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында" гы карары проектын (1 нче кушымта) Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http//aznakayevo.tatarstan.ru) веб-адресы буенча 2022 елның 22 мартыннын да сонга калмыйча урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Вахит авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес: http://pravo.tatarstan.ru ,Азнакай муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http//aznakayevo.tatar.ru//.  2022 елның 22 мартыннан да соңга калмыйча игълан итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Г.И. Аскарова